وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаh арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# ДИН вә Мәгыйшәт

**№1 (144). 6 июль 2012 / 17-шәгъбан-1433**

**ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ**


Дин һәм бүгенге дәүләтнең конституцион хокукы ▷2◁


Азаннарда гасыр авазы ▷2-3◁


Язма мәдәниятебезнең бер үрнәге ▷3-4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**МӘХӘЛЛӘ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН**

**29 июнь көнне Түбән Кама мәчетендә җомга намазы вакытында күзләренә операция кирәк булган кардәшебез Рөстәм Сәедов хакында мәхәллә халкына җиткерелде, дип хәбәр итә район мөхтәсибәте. Аллаh ризалыгын алу нияте белән, әлеге игелекле гамәлгә мөселманнар 81 мең сум акча җыйдылар. 9 июль көнне Уфа шәһәрендә Рөстәмгә операция ясаячаклар. Барлык ярдәм кулын сузучыларга Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын бирсен!**

**БУА МӘДРӘСӘСЕНӘ ЯҢА ДИРЕКТОР БИЛГЕЛӘНДЕ**

**4 июльдә Маликов Рәшид Ильяс улы Буа мәдрәсәсенә директор итеп билгеләнде. Әлеге чарада район башлыгы Әбүзәров Рафаэль Хаҗи улы, район имам-мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Хәйбуллов, Президент Аппаратыннан Илнур Илдар улы Гатауллин, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең экстремизмга каршы көрәш мәсьәләләре буенча мөфти киңәшчесе Шәкүров Равил Әнвәр улы, Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов, дин әһелләре катнашты.**

**ХАТЫН-КЫЗЛАР ӨЧЕН ДӘРЕСЛӘР БАШЛАНДЫ**

5 июльдән Казанның Салихҗан мәчетендә хатын-кызлар өчен "Ислам нигезләре" дәресләре башланды. Дәресләрне "Госмания" мәктәбенең әхлак укытучысы, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Наилә ханым Сөнгатова җитәкли. Наилә ханымның сүзләренә караганда, мондый төрдәге укулар элек Нурислам мәчетендә үткәрелгән.

**ТАТАР БҮЛЕГЕ УКЫРГА ЧАКЫРА**

**Филология һәм сәнгать институтының (КФУ) татар филологиясе бүлегендә "Филология. Татар теле һәм әдәбияты. Гарәп теле (ислам тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнү)" юнәлеше белгечлегенә бюджет урыннарга абитуриентлар кабул итү бара. Укырга керү өчен рус теле, рус әдәбияты фәннәреннән БДИ нәтиҗәләре сорала. Татар филологиясе бүлеге мөдире Флера Сәгыйть кызы Сәйфулина сүзләренә караганда, документлар 10 июльгә кадәр кабул ителә.**

**ШӘҺАДӘТНАМӘЛӘР ТАПШЫРУ ДӘВАМ ИТӘ**

5 июль көнне мөфтияттә Алексеевск һәм Биектау районы дин әһелләренә имам-хатыйблык шәһадәтнамәләре тапшырылды. Шәһадәтнамәләр тапшыру тантанасында Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз имамнарның бүгенге көндәге эшчәнлекләре турында билгеләп үтте, авыл муллаларын борчыган сорауларга җавап бирде.

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Һәр айның 24 нче числосына кадәр почтага барып "Дин вә мәгыйшәт" газетасына язылсагыз, ул сезгә киләсе ай башыннан килә башлаячак.**

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# Район имамнарына шәһадәтнамәләр тапшыру уңае белән

**Адәм баласы дөньяга килгәннән алып, киткәнчегә кадәр муллага мөрәҗәгать итә. Аллаһы Тәгалә гыйлеме белән сугарылган кешегә мулла диләр. Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап "имам" дигән төшенчә керә, имам - намазда басып торучы дип, өйрәтә башладылар. Ләкин безнең мәчет имамы ул - мулла кеше һәм имам-хатыйб булгач, намазда алда басып торучы гына түгел, гомумән, халыкны әйдәп, үзе артыннан ияртеп баручы кеше дип аңларга кирәк. Дөресен генә әйткәндә, Аллаһы Тәгалә белән гади халык арасын тоташтыра торган чылбырның бер боҗрасы.**



Гади халыкка арадашчы кирәк түгел диләр. Әмма Коръән укый белмиләр - безне чакыртып китерәләр. Бала туса да, якыннарыбыз мәрхүм булса да дога кыла алмый һаман безгә мөрәҗәгать итәләр, чөнки гамәлләребезне Аллаһы Тәгалә белән ничектер тоташтырырга кирәк. Дини белем бирергә дә мулла кирәк. Арадашчы булмыйча, кем булсын соң ул?! Милләтебезне саклау юнәлешендә дә бергәләп эшлибез.

Ничек тә мөмкинлектән чыгып, балалар белән эшләргә, халыкта әдәп-әхлак тәрбияләргә тырышыгыз. Мәчетләргә очраклы рәвештә генә бармагыз. Хәтта беркем бармаганда да, үзегез генә булса да намаз укырга йөрегез. Динне дә, дин белән бергә милләтне саклау да безнең өстә.

Сезгә олуг рәхмәтне җиткерәсем килә. Чөнки бөтенебез бергә олуг эш башкарабыз. Үзебезнең кул астында булган мәхәлләләрне туплап, әйдәп барабыз. Үзебезне дә, мәхәлләребезне дә тәрбияләргә, иманлы итәргә тырышабыз. Аллаһы Тәгалә каршында бик олы вазифа башкарабыз. Элек-электән һәм хәзер дә дин әһелләре әйдәп баручы булган, киңәшен биргән, халыкны төрле пычраклыклардан алып кала белгән, хәтта милләтне саклап калганнар. Сез бик күп эшләр башкарасыз, Аллаһның рәхмәте яусын. Сез хөрмәткә лаек кешеләр.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# Ислам дине һәм Урта гасыр сүз сәнгате

**Борынгы һәм Урта гасырларда дин дөнья халыкларының рухи һәм иҗтимагый тормышында аеруча зур роль уйнаган. Ул идеология, әдәбият һәм мәдәнияттәге төп юнәлешләрне билгеләгән. Юкка гына яһүд һәм христиан диннәренең "Библия"се, зәрдәшнең (зороастризм) "Авеста"сы, ислам диненең Коръәни-Кәриме язма мәдәниятнең һәм дөнья әдәбиятының бөек әсәрләре итеп саналмыйлар.**

VII гасырның беренче чирегендә барлыкка килгән Ислам берничә йөз ел эчендә Евразия һәм Төньяк Африкага таралып, күп кенә халыкларны һәм мәдәниятләрне үз эченә алган дөньякүләм дингә әйләнә. Бүгенге көндә Җир шарында яшәүче халыкның ? е - мөселманнар. Егерме сигез илдә Ислам дәүләт дине булып санала.

Урта гасырларда, ислам дөньясына кергән халыкларның рухи казанышларына таянып, шулай ук башка этнос һәм илләрнең тәҗрибәсен кулланып, аң-белеме һәм мәдәниятенең байлыгы, иҗади фикеренең югарылыгы, күпкырлылыгы һәм гуманистик эчтәлеге белән аерылып торган "мөселман цивилизациясе" булдырыла. Алга таба ул башка төбәкләрдәге, шул исәптән Көнбатыш Европадагы, фән һәм мәдәният үсешенә зур йогынты ясый.

Төрки-татарлар арасында ислам дине башлангыч чорында - VII гасырда ук тарала башлый. Татар дәүләтчелегенең барлыкка килүендә зур роль уйнаган Хәзәр каганлыгында (VII-X гасыр) инде 737 елда ук ислам дине дәүләт дине буларак кабул ителә. Билгеле бер дәрәҗәдә Бөек Болгарда (VII гасыр), Идел буе Болгарстанында (IX-XIII гасыр) һәм кыпчакларның дәүләти берләшмәләрендә тарала. Алтын Урда һәм аннан соңгы татар ханлыклары (Казан, Әстерхан, Кырым, Себер, Касыйм һ. б.), нигездә, мөселман илләре булалар. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: бу төрки-татар илләрендә ислам диненнән тыш башка диннәр дә булган, димәк, башка диннәргә карата сабырлык күрсәтелгән. Бу турыда Ибне Рүстә (X гасыр башы), Ибне Хаукал (X гасыр) һәм башка авторлар яза.

Идел һәм Урал буенда ислам диненең иртә таралуына карамастан, безнең көннәргә кадәр сакланган язма чыганакларда ислам диненең чагылышы бары тик X-XI гасырлардан гына күзәтелә. Моннан чыгып, төрки-татар әдәбиятын ислам диненә кадәрге һәм мөселман чорына бүлеп карарга мөмкин.

Дин һәм графика берлеге мөселман халыкларының язма һәм рухи мәдәнияте берлеген билгели.

Коръән, аның идея эчтәлеге, сюжетлары, образлары һәм стиле Урта гасыр авторларына үрнәк булып тора. Төрки-татарларның сүз сәнгате истәлекләре теге яки бу дәрәҗәдә мөселманнарның Изге Китабы белән бәйле. Мәсәлән, XIII-XIV гасырлардагы Кол Гали, Рабгузый, Мәхмүд Болгари һәм башка авторларның әсәрләре Коръән сюжетларына һәм образларына нигезләнеп язылган.



Болгар-татар шагыйре Кол Гали (1183-XIII гасырның 30 нчы еллары), Коръәннең билгеле сүрәсенә таянып, Фирдәүси, Ансари һәм башка авторларның әдәби-эстетик казанышларын файдаланып, Йосыф пәйгамбәр темасын ача. "Кыйссаи Йосыф" поэмасы, үз чиратында, башка авторларга да - бигрәк тә төрек-госманлы шагыйрьләрнең иҗатына (Шайяд Хәмзә, Әхмәди, Хәмди һ. б.) зур йогынты ясый. Йосыф турындагы сюжет күп гасырлар дәвамында татар шагыйрьләренең игътибарын үзенә җәлеп итеп тора (Әхмәтҗан Утыз Имәни (XIX гасырның беренче яртысы), Мәҗит Гафури (1880-1934)). "Кыйссаи Авык" дастанында Мөхәммәд пәйгамбәрнең (сгв) газәлине (тау кәҗәсен) кяферләрдән коткаруы, пәйгамбәрнең искиткеч сәләтләре һәм кешелеклелеге тасвирлана. Татар әдипләренең күп кенә әсәрләре Аллаһы Тәгаләне һәм Пәйгамбәребезне (сгв) мактаулардан башлана. Әдәби әсәрләрдә еш кына Коръәни-Кәрим сүрәләре һәм хәдисләр очрый.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# Ислам дине һәм Урта гасыр сүз сәнгате

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Татарлар арасында Коръәни-Кәрим, аның тәфсирләре, Пәйгамбәребезнең (сгв) хикмәтле фикерләре башта язмача, соңыннан басма формада киң таралган була.

Урта гасырларда мөселман илләрендә таралган шигъри система (гаруз, жанрлар һ. б.) татарларның сүз сәнгатендә дә тамыр җәя. Көнчыгыш мөселманнары өчен характерлы булган суфичылык төрки-татарларның да рухи тормышында киң тарала. Әхмәд Ясәви (1666 елда вафат була), Хисам Кәтиб (XIV гасыр), Колшәриф (XVI-1552), Мәүлә Колый (XVII гасыр), Шәмседдин Зәки (1821-1865) һәм башкаларның әсәрләре суфичылык рухы белән сугарылган.

"Мөселман цивилизациясе"нең үзәген гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә язылган Урта гасыр Шәрык классик әдәбияты тәшкил итә. Ул ислам дине белән тыгыз бәйләнгән, Коръәни-Кәрим фикерләре һәм ислам дине кыйммәтләре белән сугарылган. Бу әдәбият Идел һәм Урал буе халыкларына аңлаешлы булган, чөнки татарларның күпчелеге гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән, Көнчыгыш авторларының әсәрләрен язылган телләрендә һәм тәрҗемәдә укыганнар. Евразия мөселманнарының китапханәләрендә һәм шәхси коллекцияләрендә зур күләмдә гарәп, фарсы һәм төрки телләрдәге кулъязмалар һәм китаплар саклана. Әл-Газзали (1058-1111), Ф.Гаттар (1119-1223), Сәгъди (1203-1292), Низами (1141-1209), Җ.Руми (1207-1273) һ. б. әсәрләре аеруча популяр була. Мөхәммәд Чәләбинең "Мөхәммәдия" (1449) әсәрендә шигъри формада ислам диненең нигезләре һәм кыйммәтләре бирелә. Бу китап берничә гасыр дәвамында киң кулланылышта йөри. Ул Казанда берничә тапкыр басыла, дәреслек буларак мәдрәсәләрдә кулланыла, татар сүз сәнгатенә зур йогынты ясый. Г.Тукай иҗатының башлангыч чорын кайвакыт ""Мөхәммәдия" чоры" дип атыйлар.

Шулай итеп, Коръәни-Кәрим һәм ислам диненең рухи кыйммәтләре мең елдан артык төрки-татар әдәби тормышының нигезе һәм юнәлеш бирүче көче булып тора. Урта гасыр сүз сәнгате ислам диненең югары әхлакый һәм инсани идеяләре белән сугарылган һәм ул татар милләтенең үсешенә һәм саклануына зур йогынты ясый.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
**Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры**

# Бала тәрбиясе турында уйланулар

**(Ахыры. Башы газетабызның 29 июнь (№ 26) санында.)**

Кавышучыларның күбесенең аерылышуы, ятимнәр йортларының күбәюе, илдә миллионлаган сукбай балалар булуы - бар да тышкы матурлыкка гына корылган, җиңел мәхәббәт нәтиҗәсе. Бүген-иртәгә таркалырга торган гаиләдә ана карынында ук бала үзенең артык икәнен сизеп, кимсенеп яши, менә буиң зур фаҗига.

Аллаһ хәрәм иткән ризыкларны, дуңгыз итен куллану мәхәббәттә тотнаксызлыкка китерә. Хайваннар арасында ирекле мәхәббәтне дуңгызлар арасында күреп була. Шуның өчен дә дуңгыз итен күп кулланган халыкларның күбесе ирекле мәхәббәт кысаларында һәм никахсыз яшәүне өстен күрә, аларда бер-береңә хыянәт табигый халәт дәрәҗәсендә.

Әлбәттә, мәхәббәтнең иң олысы Аллаһка булырга тиеш. Ике кеше арасында булган мәхәббәт Аллаһны онытуга китерсә, бу мәхәббәт бәхетсезлеккә илтә. Аллаһка булган уртак мәхәббәт җаннарны тагын да бер-берсенә якынайта, аларны мәңге бетмәс энергия һәм илһам белән тәэмин итеп тора. Менә шушы олы мәхәббәт балага да уңай йогынты ясый. Бала бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт диңгезендә ләззәтләнә һәм аның аңында бөтен кешелек дөньясына мәхәббәт уяна. Һәм инде ул киләчәктә җәмгыятебез өчен борчу-мәшәкать тудыручы булып түгел, ә гүзәл шәхес булып формалаша. Аллаһ мәңгелек, Аның, кешеләргә мәхәббәте дә мәңгелек. Кем шуны таный, шушы мәхәббәткә кушыла ала икән, ул - бәхетле. Тормышта нинди генә сынаулар булса да, андый кеше ул сынауларны уңышлы үтәргә үзендә көч таба. Чөнки ул бетмәс энергия һәм мәрхәмәт чишмәсенә тоташа.

Никах ул - бер-берсен ошаткан җаннарның үз хисләрен җәмгыятькә белдерүләре, "Аллаһ кушканча яшәрбез", - дип, бөтен кешелек алдында вәгъдә бирүләре. Әгәр алар тормышларын Аллаһ кушканча көйли алсалар, бу никахның нәтиҗәсе игелекле бала булачак. Андый бала ана карынында ук инде үзен җәмгыятьнең тулы хокуклы, чын шәхесе итеп сизәчәк һәм бу, әлбәттә, киләчәктә дә аның холкында чагылыш таба. Әгәр дә кешеләр никахсыз яшәсәләр, никахсыз гына ана карынына орлык төшсә, андый бала үзен ана карынында ук гаепле, кимсетелгән, рәнҗетелгән итеп сизәчәк һәм үпкә хисе белән дөньяга киләчәк. Җәмгыятьтә урынын табу аңа кыен булачак.

Никахка салкын карау, никахсыз яшәү - ул киләчәк буын алдында җинаятькә тиң. Кем бүген ирекле мәхәббәт турында сүз алып бара, гаиләнең, никахның әһәмиятен киметергә тырыша, ул кеше - милләтнең киләчәгенә балта чабучы.

Күпләр тарафыннан тискәре бәяләнә торган, дүрткә кадәр хатын алуга шәригатебездәге рөхсәт тә - һәр анага никахлы бала табу өчен бирелгән мөмкинлек. Бүген илебездә хатын-кызларның саны ирләрнекеннән ун миллионга артык. Димәк, безнең закон буенча, ул - ун миллион хатынның никахлы ирдән бала алып кайтырга хакы юк, дигән сүз. Алып кайтсалар да, законсыз, никахсыз гына балага узып, җәмгыятебезгә кыерсытылган рухлы балалар алып кайту. Ә моның тискәре нәтиҗәсеннән шул җәмгыятебез иза чигәчәк бит. Аллаһның бер генә хөкеме дә урынсыз түгел, барысы да кешелек дөньясына хезмәт итә. Үзебезнең зәгыйфь акылларыбыз белән Аллаһның аятьләренә тәнкыйть күзе белән карап, көферлеккә төшә күрмик.

***Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,***
***Татарстанның баш казые***

2012 ЕЛ - ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ

# Азаннарда гасыр авазы

**Мамадыш районында бүгенге көндә 54 мәчет эшләп килә. Узган ел гына ачылганнары да бар. Ә менә Түбән Ушмы мәхәлләсенең Таш мәчете үзенең 110 еллыгын билгеләп үтте. Тагын кайда бар мондый чал тарихлы һәм заманча гыйбадәтханә?!**

"XIX гасыр ахырында авылыбызда дүрт мәхәллә булган. Бүгенге көндә эшләп килүче икенче мәхәллә мәчете 550 нче санлы. Ул башта агачтан салынган була. 1897 елның 23 июлендә яна. Аның урынына таштан мәчет күтәрәләр. Ярдәм сорап Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре Әхмәтгали улы Хөсәеновка мөрәҗәгать итәләр. Казан һәм Оренбург губерналарының төрле төбәкләрендә 20 дән артык мәчет һәм мәдрәсә торгызган бай төзелешкә акча бирә. 1898 елның 3 февралендә икенче мәхәлләнең 420 ир-аты килешү төзеп, мәчетнең проектын һәм сызымын әзерләтәләр. Моны Габдулла Мансуров башкара. Шул ук елның 18 маенда Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлеге проектны раслый һәм төзелеш эшләре башлана. Анда бөтен авыл катнаша. Ташны күрше авыллардан да ат белән китерәләр. Ике ел дигәндә 26х10 метр үлчәмендәге мәһабәт бина калкып чыга. Ул тыш яктан бик матурлап бизәлә, кырын җиргә салынганлыктан, михраб ягыннан караганда ике катлы йортны хәтерләтә. Борынгы стильдә эшләнгән манара башындагы ай бөтен тирәякка ямь бирә. XIX гасыр башында мәчет манарасыннан беренче азан тавышы яңгырый. Аны әйтүчегә зурлап бүләк тапшыралар. Мәчетне ачканда күрше авыллардан да халык бик күп җыела. Әхмәтгали бай Хөсәенов килми. "Мәчет болай гына эшләнергә тиеш түгел иде!" - ди. Таш мәчет бик матур ак таш стеналар белән әйләндереп алына. Капкалар да матурлап эшләнә. Шул чордан башлап, авылның күрке булган Таш мәчет (аңа шулай дип исем бирәләр) халыкка армый-талмый хезмәт итә. Узган гасырның 30 нчы елларында әле мәчеттә гыйбадәт кылалар иде, чөнки без, малайлар, ахшам намазы алдыннан таш мәчеткә җыелып, мөәэзиннең азан әйткәнен көтә идек. Ул әйтә башлауга, бөтен көчкә узыша-узыша: "Ахшам кычкырды!" - дип сөрән салып, урам буйлап өйләргә чабыша идек. Бу ураза вакыты булгандыр, өйләрдә сәгатьләр юк, сәгать ролен без үтәгәнбез. Ул елларда Таш мәчеттә имам Сосновка ягыннан килгән Мөгыйм мулла була, хатыны Зәкия абыстай. Аларны халык бүген дә хөрмәтләп искә ала. Алар халыкка аң-белем бирү, дини агарту юнәлешендә армый-талмый эшләгәннәр, иман нуры сеңдереп, ислам әхлагы тәрбияләргә омтылганнар", - дип яза "Мамадышым - язмышым" энциклопедик басмасында Түбән Ушмы имамының беренче ярдәмчесе Камил Тимербаев. Ул бу мәгълүматларны Алабуга архивы һәм халык истәлекләренә таянып туплый.

Авылның кече абыстае Флёра Мөхәммәтшина да "Түбән Ушмы авылының мәчетләре тарихы" дип исемләгән альбомында тарихи кызыклы фактларны бик җентекләп терки. "Мәхәллә белән 1862 елда наставник итеп сайлап куелган Фәхретдин Төхфәтуллин (Дусаев) 50 ел алмашынусыз идарә итә. 1863 елда Баһаветдин Сираҗетдиновны билгелиләр. Мәчет каршында мәдрәсә дә эшләп килә. Анда сөннәт бүлмәсе дә була. 30 нчы еллар башына кадәр авылда дүрт мәхәллә мәчете дә дин тотучыларга барлык шартларны тудыра. Халык анда теләп йөри. Сугыш алды елларында динне җимерү, муллаларны кулга алу башлана. Авылдагы өч агач мәчет замана шаукымы корбаны була. Руханиларның йорт-җирләре тартып алына, алар яшь балалары белән урамга куып чыгарыла, атыла, Себергә сөрелә. Мөселманнарның иң изге хисләрен аяк астына салып таптаучы эш-гамәлләр кылына: мәчетләрне ябып, анда дуңгыз асраулар, изге китапларны җыеп янды-

***(Ахыры 3 нче биттә.)***

# Дин һәм бүгенге дәүләтнең конституцион хокукы

**Россия күләмендә караганда Татарстан мөселманнар күп яши торган төбәкләрнең берсе булып санала. Ата-бабаларыбыз Болгарда Исламны кабул иткән, шулай ук Россиядә басма Коръәнне беренчеләрдән булып нәшер иткән. Әлбәттә, тарихи, иҗтимагый яктан караганда тормышыбыз Ислам белән тыгыз бәйләнештә. Әмма, башка мөселман илләреннән аермалы буларак, без дөньяви дәүләттә яшибез. Дөньяви дәүләттә гражданнар хокукы Конституциягә нигезләнгән.**

Бүгенге көндә сәяси, икътисади, хокукый өлкәләрдә дини төшенчәләр көннән-көн ешрак очрый. Бердән, моңар мөселман илләре белән алып барылган хезмәттәшлек этәрсә, икенчедән, җәмгыятьтә диннең киң таралыш ала баруы йогынты ясый. Димәк, дин һәм бүгенге дәүләтнең конституцион хокуклары турында ныклап уйнарга вакыт җиткән.

30 июнь көнне Казан (Идел буе) федераль университетының юридик факультеты Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә "Дин һәм бүгенге дәүләтнең конституцион хокукы" дип аталган "түгәрәк өстәл" утырышында сүз әнә шул хакта барды. Коръән елы уңаеннан уздырылган чираттагы "түгәрәк өстәл"дә ТР Президенты Аппараты, ТР Дәүләт Советы, ТР Югары суды, ТР Прокуратурасы, Россия ислам университеты, Казан Епархиясе, Иран, Төркия консуллыклары вәкилләре катнашты.

Мөфтиятнең уку-укыту бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов катнашучыларны мөфти Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән сәламләде. Ул үзенең чыгышында агымдагы елның Коръән елы буларак үткәрелүе зур игътибарга лаек күренеш булуын һәм "түгәрәк өстәл"нең мөһимлеген ассызыклады. "Бу түгәрәк өстәлне үткәрү бик актуаль. Хокук өлкәсе вәкилләренә дә, канун чыгаручыларга да Коръәнне белү, өйрәнү кирәк. Чөнки Коръән меңләгән кешеләрнең тормышына йогынты ясый. Ул мөселманнар өчен хокук чыганагы булып тора", - диде Вәлиулла хәзрәт.

Татарстан прокуроры Кафил Әмиров исә иң беренче чиратта дин һәм хокук өлкәләренең бүгенге җәмгыятьтә ни дәрәҗәдә бәйләнелеген күрсәтергә омтылып саннарга тукталды. "Татарстан күпмилләтле һәм күпдинле республика. Илледән артык төрле милләт, уннан артык төрдәге конфессия вәкилләре яши. Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап ислам динен тотучылар 300 меңгә арткан. Республикада барлыгы 1514 дини оешма рәсми төстә теркәлгән. Татарстанда барлык төр диннәрнең хокуклары һәм аларның дөньяви аспектлардан ераклыгы бертигез рәвештә саклана", - диде Кафил әфәнде. Аннары ул хәтта совет заманнарында да Казан губернасында яшәүче мөселманнарның хокук өлкәсенә кагылышлы мирасын җыю бик сакчыл алып барылуын искә төшерде. Монна тыш, ул дин һәм бүгенге дәүләтнең конституцион хокукы дигәндә, беренчел итеп икътисадтан бигрәк, рухи кыйммәтләр турында сөйләшү кирәклегенә басым ясады.

Йомгаклап әйткәндә, мәртәбәле юристлар, хокук саклау органнары җитәкчеләре һәм, әлбәттә, дин әһелләре Татарстанның яңа идеяләрне тормышка ашыруда үзенә күрә бер мәйданчык булуын искәртеп, дин белән конституцион хокуклар арасында үзара диалог корылуын һәм бу өлкәдәге мәсьәләләр белән шөгыльләнүче аерым дәүләт структурасы кирәклеген куәтләде.

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъват һәм мәгълүмат бүлеге***



# Язма мәдәниятебезнең бер үрнәге

**Иске Рәҗәптә (Спас районы) Нугаевлар гаиләсендә саклanган шәҗәрә турында ишетеп белсәм дә, үз күзем белән күрергә туры килгәне юк иде. Татар халкы үзен ерак гасырлардан килгән борынгы халык дип саный. "Җиде буынны белү", үз гаиләсенең нәсел-нәсәбен бер җепкә тезеп шәҗәрә төзү белемле гаиләләргә хас күренеш. Кайбер шәҗәрәләрдә нәсел очы болгар бабаларыбызга, тарихта эз калдырган затлы нәселләргә, хәтта Мөхәммәт пәйгамбәрнең якыннарына барып тоташа. Бу традиция бүгенге көнгә кадәр сакланып килә. Шуңа күрә Иске Рәҗәптә шундый бер шәҗәрә саклануы гәҗәп түгел.**



Ләкин шәҗәрәне кулга алу белән, анда бер генә хатын-кыз исеме булмавы мине бераз шөбһәгә төшерде. Аннан соң исемнәр төрле төстәге, төрле зурлыктагы түгәрәкләр белән әйләндереп алынган. Ни өчендер шәҗәрәнең башында һәрбер кеше исеме төсле түгәрәкләр эченә алынган, ә соңрак алар бик сирәк очрый. Биш метрга якын озынлыктагы шәҗәрәнең уртасына җиткәч яшел, кызыл төсләргә бизәлгән, бүтәннәргә караганда ике мәртәбә зуррак булган түгәрәк эчендә "Хәзрәте хуҗа Базырык, хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди" исемен укыгач кына шәҗәрәнең серенә төшенә алдым. Бу Нәкышбәнди тарикатенең силсиләнамәсе иде.

Нәрсә соң ул силсилә? Гарәпчәдән тәрҗемә итсәк, силсилә бер-берсенә бәйләнеп килгән рухи туганлык чылбыры - шәҗәрә була. Нәсел-нәсәб шәҗәрәсе ата-ана - бала тәртибендә төзелсә, силсилә остаз - укучы тәртибендә төзелә. Силсиләләр төзү XIV йөздән башлап мөселманнар яшәгән төбәкләрдә тарала. XII-XIII йөзләрдә үк Урта Азия җирендә халык арасында аерым юнәлештә баручы мөселманнар оешмасы - тарикатләр формалаша башлый. Билгеле булган мөселманнар дини юнәлешнең киң таралганы суфичылык юлыннан баручы Нәкышбәнди тарикатендә була.

Хуҗа Баһаветдин Мөхәммәт Нәкышбәнди (1318-1389) бөтен гомерен Бохарада яши. Аның беренче остазы Баба Симаси була. Ул тормышта үзен бик гади тота. Үз хезмәте белән көн күрә, ипи-суга канәгать була, хезмәтчеләр тотуны зур гөнаһ саный. Үлгәннән соң изгеләр рәтеннән саналып, 1554 елда ук кабере өстенә мавзолей корыла.

Нәкышбәнди тарикатнең 11 принцибын төзеп халыкка җиткерә. Аларның иң әһәмиятлеләре: рухи чисталык, байлыкка табынмау, тыйнаклылык, зекерне (Аллаһы Тәгаләне олылау) тыныч кына әйтү. Дин галимнәре зекерне тормышның иң әһәмиятле өлеше дип санаганнар, чөнки зекерне даими һәм дөрес итеп әйтү кешене Аллаһы Тәгаләгә якынайта дип саналган. Зекер тыныч кына авыз эченнән яисә кычкырып әйтелә. Тора-бара, зекерне тыныч яисә кычкырып әйтү мөселманнар арасындагы төп аермалыкка әйләнә.

Нәкышбәнди үзенең тарикатендә суфичылыкка нигез салучылардан Габделхалыйк Гиждувани (1180 елда вафат була) һәм Әхмәт Ясәви (1166 елда вафат була) тәгълиматларына таяна.

Силсиләгә әйләнеп кайтсак, ул ике өлешкә бүленә. Беренчесе - "алтын чылбыр", ягъни Нәкышбәндидән алып Мөхәммәт пәйгамбәргә кадәр өлеше - тәрбия шәехләре була. Икенче өлеше - тәрбия силсиләсе - Нәкышбәндидән соң килгән, аның белемен үзләштергән кешеләр.

Безнең кулыбыздагы силсиләнең "алтын чылбыр"ның башындагы Мөхәммәт пәйгамбәр һәм беренче хәлифәләрнең исемнәре булган өлеше ертып алынган. Әмма хәзрәти Галинең уллары Хәсән белән Хөсәеннең исемнәре бар, яннарында "әмир әл-мөэмин" титулы да бар. Шәҗәрәнең башында беренче рәттә Мөхәммәт пәйгамбәрнең көрәштәшләре Сәлмән Фариси, Хәсән Басри исемнәре ачык укыла. Алар Хөсәен белән бергә силсиләгә нигез салучылардан саналалар.

Шәҗәрәдә рухи туганлыкны күрсәтүче сызыклар Җәгъфәр бине Садыйк һәм Солтан Ибраһим Әдһәм исемнәре тирәсендә төрле якка таралып китә.

Силсиләнең төп сызыгы уң яктан Ибраһим Әдһәм һәм Әбу Йосыф әл-Бистами аша аларның күп санлы укучыларына юнәлә. Шуларның, ике кат бөҗра белән әйләндереп алынган, берничәсенә генә тукталып үтик. Аларның иң танылганнары әл-Газзали һәм Хамадани булырлар.

Әбу Хәмит Мөхәммәт әл-Газзали мөселмән дөньясының иң танылган галим-философларының берсе. Аңа галимнәр арасында беренчеләрдән булып "ислам тәгълиматын раслаучы" дигән мактаулы исем бирелә. Танылган суфи Әбу Йосыф Хамадани суфилар туганлыгының төп принципларына нигез салган әл-Гиждуванины тәрбияләп үстерә.

Бу хөрмәтле галимнәр белән беррәттән тагын берничә исемне атап китәргә кирәк: Әбу Нәҗиб Сухраварди (1145-1168), Шиһабетдин Сухраварди, Нәҗметдин Кубра (1145-1221). Соңгысы Кубравия тарикатенә нигез сала.

Суфиларның аерым төбәкләрдә үз тарикатләрен оештыручылар шәҗәрәдә төсле түгәрәкләр белән билгеләп үтелгән. Кайберләрен генә булса да санап китик: Гали Хамадани (1314-1385), Рукетдин Симнани (1261-1336), Сәйфетдин Бахарзи, Баба Симаси (1340 елда үлә), Гәләветдин Гаттар (1400 елда үлә).

Шәҗәрәдә төсле түгәрәк белән билгеләнмәгәннәр арасында да таныш исемнәрне очратырга була. Беренче чиратта мин Габдрахман Җами һәм Җәләлетдин Руми исемнәрен атар идем.

Җәләлетдин Мөхәммәт бин Баһаветдин 1207 елның 30 сентяберендә Балх шәһәрендә (Әфганстан) дөньяга килә. Аның атасы Баһаветдин Вәлид (шәҗәрәдә аның исеме дә бар) "галимнәр падишаһы" буларак таныла. Аның әбисе Харәземшаһлар нәселеннән булса, әнисе Бәлх шәһәре әмире кызы була. Димәк, Җәләлетдингә үз чорында төпле югары белем алырга бөтен мөмкинчелек була. Аның атасы Нәҗметдин Кубра, әл-Газзали тәгълиматларын укып, өйрәнеп улын да суфилык рухында тәрбияли. Урта Азиягә монгол һөҗүме алдыннан аларның гаиләсе Төркиягә Селҗуклар башкаласы Конья шәһәренә күчеп килә.

Җәләлетдин Руми 500 дән артык китап яза һәм мөселманнар арасында гына түгел, христианнар, яһүдиләр арасында да зур шагыйрь булып танылa. Шуңа күрә шагыйрьне соңгы юлга озатырга бөтен халык чыга.

Руми, бүген дә әсәрләре иң яратып укыла торган шагыйрьләрнең берсе. Англиядә аның әсәрләре тиражы буенча Шекспирны уздыра, Шәрык илләрендә Коръән һәм хәдисләрдән кала өченче урында бара. Россия җирендә Руминың биографиясе "Атаклы кешеләр тормышы" сериясендә дөнья күрде. Аның әсәрләре 20 телгә тәрҗемә ителгән. Җәләлетдин Руми үзенең әсәрләрендә күңел тынычлыгы, дәрәҗәсенә карамыйча һәрбер кешегә ихтирам, азатлык идеяләрен күтәреп чыга, мәхәббәт җырчысы буларак танылa. Шуңа күрә, бүгенге катлаулы дөньяда да аның әсәрләре кешеләр күңеленә юл таба.

Силсиләнең сакланып калган өлешендә 487 исем бар. Ул кешеләрнең күбесенең тормыш юлы Үзәк Азия (Иран, Ирак, Әфганстан, Үзбәкстан) белән бәйләнгән, кайберләре Кытай, Һиндстан, Индонезия, Төньяк Африка һәм башка җирләрдә ислам дине таратып, суфилар туганлыгына нигез салалар. Безгә, әлбәттә, суфичылыкның төрки халыклар арасында һәм Идел буенда таралуын белеләү мөһим. Бу өлкәдә Хуҗа Әхмәт Ясәвинең һәм аның укучысы Хәким Атаның роле бик зур. Соңгысы татарлар арасында Сөләймән Бакыргани исемендә билгеле. Төркиләр нәсел-нәсәбе силсиләнең уң ягында аерым сызык белән күрсәтелгән. Ул, югарыда күрсәтелгән ике исемнән башка, Баба Мичин, Ходайдад, Садри Ата, Гали Шәех, Шәех Мөрид, Җәләлетдин исемнәрен берләштереп Касыйм шәех исемендә өзелә.

Дөньяда танылган халыкара төрки тарихи һәйкәлләрне саклау оешмасы ТЮРКСОЙ 2003 елда Хуҗа Әхмәт Ясәвинең тууының 900 еллыгын зурлап бәйрәм итте. Туган шәһәре Төркстанда (Казакъстан) аның кабере өстендә XVI йөздә үк корылган мавзолеена реставрация ясалды. Аның янында борынгы стильдә эшләнгән кунакханә һәм килгән мосафирлар өчен бөтен мөмкинчелекләре булган үзәк корылды.

Шул көннәрдә Татарстанда аның әсәрләре басылып чыкты. Җыентыкта силсиләдә исемнәре аталган Сөләймән Бакыргани, Баба Мичин, Ходайдад, Касыйм шәех һәм Казан ханлыгының атаклы шәхесе Кол Шәрифнең шигырьләре урнаштырылган.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Азаннарда гасыр авазы

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

рулар, дини бәйрәмнәрдә мәчет тирәсендә төрле уеннар оештырып, такмак җырлау дисеңме, берсе дә калмый. Таш мәчетне сүтә алмыйлар. Киселгән баганаларны болтлар белән ныгыталар, кабат бу эшкә тотынучы булмый. Шулай итеп, манара исән кала. Шул вакыттан башлап бина колхоз карамагына күчә. Сугыш чорында биредә балалар бакчасы, аннары клуб, ашлык саклау склады була. Вакыт, табигать шартлары үзенекен итә, түбә калае туза, бер почмактан су үтеп, таш араларын юа, михраб җимерек хәлгә килә. Узган гасырның 70 нче еллары ахырында колхоз рәисе Мөхәммәтҗан Шакиров, беркемнән рөхсәт сорап тормыйча, түбәне цинкланган калай белән яптыра, михрабны ныгыттыра, манараны төзәттерә, мәчеткә яңа ай куйдырта. Колхоз рәисенең Аллаһ йортына булган мөнәсәбәте бер имансыз бәндәгә ошамый һәм ул обкомга хат юллый. Нишләргә?! Мөхәммәтҗан Шакир улы югалып калмый. Мамадышка сәнгать остаханәсенә бара да, "Түбән Ушмы авылының тарихын өйрәнү музее" дигән элмә такта яздыра. Колхозның ун меӊ сум акчасына төрле экспонатлар, кирәк-ярак табалар. Мәктәп музееның барлык экспонатларын шунда күчерәләр. Мәктәп директоры Салих Шакиров, укытучы Хөсәен Сәләхетдинов, пионервожатый Флера Мөхәммәтханова музей ачуга зур көч куялар. Казаннан шикаять тикшерүчеләр килгәндә музей әзер була. Карап чыгалар, башлангычны бик хуплыйлар, мактап, рәхмәтләр әйтеп кайтып китәләр. Шулай итеп, Түбән Ушмыда беренче авыл музее оештырыла һәм мәчет тагын җимерелми кала. Таш мәчет, Аллаһның рәхмәте белән, авыр заманнарны имин кичерә һәм бер гасырдан артык дингә хезмәт итә. Мондый ислам символы булган мәчетләр Татарстанда тагын бармы икән?!"

Түбән Ушмы авылының аксакалы, мәчет карты безгә менә ниләр сөйләде: "Үзгәртеп кору елларында авыл картлары Нурулла Хәбибуллин өендә намаз укыйлар. Имам булып Динмөхәммәт Һадиуллин эшли. Хөкүмәт мәчетләрне ачарга рөхсәт итә. Мәчет төзек, ләкин анда музей. Аны мәктәпкә күчереп, мәчетне дингә бирергә дигәч, каршы чыгучылар табыла. Музей әһәмиятлерәк, имеш. 1990 елда мәчет яңадан ачылды. Гасыр эчендә тышкы һәм эчке яктан нык таушалган мәчетне 2004 елның көзендә күмәк хуҗалык рәисе Рафаэль Ясәви улы Мөхәммәтшин җитәкчелегендә, авылдашларның да матди ярдәме белән көн таләпләренә туры китереп ремонтладык, җиһазладык, яңарттык. Бик зур, саваплы гамәл кылынды. Имамлык вазыйфасын Камил Тимербаев үти башлады. Әнәс Мостафин, Әхмәт Ясәвиев, Гали Гыйльфанов мөәзин булдылар. Аннан соң бу изге эшне Мөбарәкҗан Вахитов, Нургаян Мөхетдиновлар башкарды. Ачкыч хәзер мәдрәсә тәмамлап кайткан яшь хәзрәт Илнар Фәхретдиновка тапшырылды. Иман йортының эшеннән авыл халкы канәгать. Җомга намазына иләлеләп кеше йөри. Дини бәйрәмнәр оешкан төстә уза. Хатын-кызлар бик актив. Мамадыштан Мәскүрә һәм Сәкинә (урыны җәннәттә булсын) абыстайлар килеп, бик күпләргә Коръәнне гарәп телендә укырга өйрәттеләр. Халык өлкән абыстай Асия Галиеваның вәгазьләрен рәхәтләнеп тыңлый". Авыл халкы бу тарихи, серле, изге бина белән чиксез горурлана.

Нинди буталчык заманнарда да үзенең тышкы кыяфәтен, асылын саклап калган мәчеткә "Татарстан мәчетләре" китабында аерым бит багышланган, аның тарихы интернет челтәренә дә урнаштырылган.

**Алсу ДИЯР,**
**Мамадыш районы**



# Язма мәдәниятебезнең бер үрнәге

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Әхмәд Ясәвинең ислам дөньясында нинди олы шәхес икәнен аңлау өчен Сөләйман Бакырганинең дүртьюллыгын китерү дә җитә.

Исхак баба нәселе,
Шәех Ибраһим колыны,
Шәехләрнең олысы,
Шәйхем Әхмәд Ясәви
Урны дәрес - сәламдә (җәннәт),
Шәйхем Әхмәд Ясәви

Әйтеп үтелгән Касыйм шәех силсиләдәге җепләр аша Гобәйдулла Ахрар чылбыры белән тоташа.

Гобәйдулла Ахрар (1404-1490) - Тимурилар чорының иң атаклы шәхесләренең берсе. Ул чорда Нәкышбәнди суфилар туганлыгы оешмалары Урта Азиядә һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр арасында, шулай ук төрки халыклар арасында киң тарала. Гобәйдулла ханнар нәселеннән булмаса да, 40 ел буена Урта Азиядә идарә итә, чөнки ул дәүләт башында торучылар арасындагы төрле каршылыкларны үз мәнфәгате өчен бик оста файдалана. Суфилык идеясенә кайбер ханнар да тартыла. Мәсәлән, шәҗәрәдә исеме аталган Ак Көенле әмире Озын Хәсән (1408-1478).

Идел буенда Нәкышбәнди суфилык идеясенең таралуын Хуҗа Әхмәт Ясәви яисә Гобәйдулла Ахрар исеме белән бәйләп карасаң да, ул Төркстан һәм Өст Йорт (Казакъстан) аша үтеп керүе тарихи факт. Биредә мөселман язма культурасы төрки халык традицияләре белән бәйләнеп төрки-татар җирлегенә яраклаштырыла.

Нәкышбәнди тарикатенең соңгы көчле шәхесләреннән Хуҗа Әхмәд Кассамины санарга була. 1549 елны ул үлгәннән соң Идел буе тарикате белән Урта Азия арасында бәйләнешләр туктала.

Нәкышбәнди силсиләсе фәнни әдәбиятта басылып чыкмаган, әмма Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә аның ике данә саклануы билгеле.

Әсгат хәзрәтнең әйтүенә караганда, силсиләнең башы һәм соңгы өлеше узган гасырның 60 нчы елларында гына ертылган. Анда хәзрәтнең атасы һәм анасы ягыннан булган туганнарының исемнәре булган.

Ул исемнәрнең кайберләрен Иске Рәҗәп авылы зиратында сакланган кабер ташыннан укырга була. Хөсәен, Габделваһаб, Лотфулла, Мансур, Нурҗәлил, Габделгазиз, Әхмәт. Алардан Габделваһаб, Лотфулла, Габделгазизларның Иске Рәҗәпнең 1-3 мәхәллә мәчетләрендә имам булулары билгеле.

Хәзрәтнең әйтүенчә, аларның нәсел-нәсәбе Чардаклы районы Иртуган авылыннан Габделҗаббар Кандалыйга һәм Кизләү мәдрәсәсе имамнарына барып тоташа. Кизләү мәдрәсәсендә кульязма китапларны күпләп күчерү белән шөгыльләнгәнгә күрә, силсилә дә шул мәдрәсәдә күчерелгәндер дигән фикер бар.

***Җәмил МӨХӘММӘТШИН,***
***Болгар тыюлыгы фәнни хезмәткәре,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре***

# Уразага әзерләник!

**Вәлиулла хәзрәт Якуповның “Рамазан. Ураза” дип аталган китабының икенче басмасы дөнья күрде. “Иман” нәшриятында басылган татарча китапның исеме үк аның ни турында икәнен әйтеп тора. Әлеге китапта ураза тотуның мәгънәсе аңлатыла. Моннан тыш, ул ураза тотарга ният итүчеләргә көндәлек кулланма буларак та хезмәт итәрлек басма.**




Китап авторы Вәлиулла хәзрәт Якупов ураза тоту тәртипләрен бөртекләп язган һәм киңәшләрен дә биргән. Уразага кагылышлы сорау-җавап бүлеге күпләргә үзләрен борчыган мәсьәләләрне чишәргә булышыр. Китапта Рамазан аенда укыла торган догалар, ният әйтүләр дә урын алган. Шулай ук анда быелгы һәм киләсе елгы Рамазан аена сәхәр, ифтар һәм намаз уку вакытлары күрсәтелгән.

Вәлиулла хәзрәт үзенең китабында Рамазан ае, ураза тоту турында дини күзлектән чыгып кына язмый. Бу дини төшенчәләрнең иҗтимагый әһәмияткә ия булуы турындагы язмалар – яңа басманың үзенчәлеге. Әйтик, аерым бер бүлектә уразаның сәламәтлеккә файдасы турында язылган.

# Көчле кешене мәрхәмәтлелек бизи



**Кечкенә Самирага әле ике яшь тә тулмаган, ләкин ул бу гүзәл дөньяның төсләрен күрү бәхетеннән мәхрүм - бөтенләй күрми диярлек, ДЦП (церебраль паралич) булу сәбәпле, башка балалар кебек йөреп китә алмый.**

Табиблар куйган диагноз - "Последствия перенесенной краниоспинальной травмы в сочетании с гипоксически-ишемическим поражением ЦНС (центральной нервной системы)".

Шулай да Украинада урнашкан халыкара клиникада (http://www.reha.lviv.ua) дәвалану мөмкинлеге бар. Акча гына кирәк.

Дуслар, сабыйга тормышның бар ямен тоярга булыша алабыз! Аңа ярдәм кулы сузсак, ул да, сезнең кебек үк, ямьле җәйгә, кошлар сайравына, матур болын чәчәкләренә сокланыр иде.

Моның өчен финанс ярдәме кирәк. Әйдәгез, ярдәмгә ашыгыйк! Бәлки бу дөньяда ук кылган игелекле гамәлләребез үзебезгә әйләнеп кайтыр, хыялларыбыз тормышка ашар.

"Көчле кешене мәрхәмәтлелек бизи", - диләр мөселман Көнчыгышында.

**ГАЙНЕТДИНОВА САМИРАНЫҢ ӘТИСЕ ЯЗГАН ХАТ:**

"Камилла белән Самира - игезәкләр. Алар җитлекмичә туды. Камиллага тугач ук күзләренә операция ясадылар. Ул хәзер яхшы күрә. Ә Самирага табиблар операция кирәк түгел, диделәр. Бер яшенә кадәр ул бик начар күрә иде. Хәзер дә 30 процент кына күрә.

ДЦП аркасында ул үрмәли дә, утыра да, йөри дә алмый. Хәлләр яхшы түгел.

Кышын Мәскәүдә дәваланып кайттык, Казанда даими дәваланабыз. Күптән түгел генә инвалидлык бирделәр. Табиблар, баланы чит ил клиникаларында яисә Украинада аякка бастыру мөмкин булыр, диләр. Кая гына барсак та, бездән акча гына каералар, ә нәтиҗә юк. Ни кызганыч, мин бу сүзләрне Казан клиникалары турында әйтәм. Менә шундый хәлләр..."

**АКЧА КҮЧЕРҮ ӨЧЕН СЧЁТ:**

Банк получателя: отделение "Банк Татарстан" 8610 г. Казань
БИК 049205603
ИНН 7707083893
КПП 165902001
К/счёт 30101810600000000603
Счёт № получателя 30301810842006006221

**РЕКВИЗИТЫ:**

Получатель платежа: ООО "ДЕНЬГИ.МЭЙЛ.РУ"
ИНН: 7714782518
Расчетный счет: 40702810000002419193
БИК: 044525700
КПП: 771401001
Банк: ЗАО "Райффайзенбанк"
К/счёт: 30101810200000000700
Вид платежа: Зачисление для пользователя Деньги@Mail.Ru: 1027 6001 1224 0969

*Контактный телефон: 89872639889 (Гульнара) - отдел благотворительности и социальной помощи Духовного управления мусульман РТ*




## ООО «Ритуальные услуги»

**Изготовление памятников и оград**

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница -
с 9:00 до 18:00,
суббота - с 9:00 до 13:00.
**Тел.: 225-28-90, 293-25-61**

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00,
вторник - выходной.
**Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93**

**На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.**
**Тел. 297-28-90**

Реклама


## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 7.07.12 | 2:39 | 4:09 | 13:02 | 18:39 | 21:27 | 22:57 |
| Якшәмбе | 8.07.12 | 2:41 | 4:11 | 13:02 | 18:38 | 21:26 | 22:56 |
| Дүшәмбе | 9.07.12 | 2:42 | 4:12 | 13:02 | 18:37 | 21:25 | 22:55 |
| Сишәмбе | 10.07.12 | 2:43 | 4:13 | 13:02 | 18:37 | 21:24 | 22:54 |
| Чәршәмбе | 11.07.12 | 2:44 | 4:14 | 13:02 | 18:36 | 21:23 | 22:53 |
| Пәнҗешәмбе | 12.07.12 | 2:46 | 4:16 | 13:02 | 18:35 | 21:22 | 22:52 |
| Җомга | 13.07.12 | 2:47 | 4:17 | 13:02 | 18:35 | 21:21 | 22:51 |
| Шимбә | 14.07.12 | 2:48 | 4:18 | 13:02 | 18:34 | 21:20 | 22:50 |







**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №1 (144) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9406.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 5 июль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).


**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклаңыгыз!**